КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 май г.Казань № 420

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 май, 374 нче; 2020 ел, 17 май, 398 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 10 нчы пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«раслый торган документлары булганда Татарстан Республикасына турыдан-туры килү алдыннан Россия Федерациясе тиешле субъектларының баш дәүләт табиблары карарлары нигезендә Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә обсерватор шартларында изоляциядә булган затларга, медицина оешмаларының раслый торган документлары булганда яңа коронавирус йогышлы авыруы белән авырып алган затларга, шулай ук Татарстан Республикасына килүгә кадәр ике көннән дә иртәрәк булмаган вакытта полимераза чылбырлы реакциясе ысулы белән яңа коронавирус йогышлы авыруына алынган биоматериалны тикшерү

нәтиҗәләре тискәре булганда яңа коронавирус йогышлы авыруы билгеләре булмаган затларга.».

2. Бу карар, рәсми басылып чыккан көннән бер көн үткәч, үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин